ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 июнь 2026 ел

№ 6167

Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында

Россия Федерациясенең «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Законы, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия төзергә.

2. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Руководитель
Исполнительного комитета Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 19 июнендәге
6167 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә
Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссиянең (алга таба - комиссия) бурычларын, эш тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Законына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан 2025 елның 30 августындагы МД-П4-32257 номеры белән расланган Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча ярдәм тәкъдимнәргә таяна.

2 бүлек. Комиссиянең төп бурычлары

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

1) гражданнарның, дәүләт, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның (алга таба - граждан, оешма) Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү турында үтенечләрен (гаризаларын) карап тикшерү;

2) Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча карарлар кабул итү;

3) комиссия карары үтәлешен контрольдә тоту.

3 бүлек. Комиссиянең эш тәртибе

4. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

5. Комиссия рәистән, рәиснең ике урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

6. Комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә ике мәртәбә үткәрелә.

8. Комиссия, аның әгъзаларының кимендә яртысы булганда, утырышлар үткәрергә һәм карарлар кабул итәргә хокуклы.

9. Комиссия карары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

10. Ватанны саклаучының истәлеген мәңгеләштерү турында гариза белән түбәндәге категория гражданнар мөрәҗәгать итә ала:

1) якын туганнары (ире, хатыны, балалары, ата-аналары, ир туганнары һәм кыз туганнары);

2) һәлак булган кеше хезмәт эшчәнлеген алып барган Яр Чаллы шәһәре оешмасының җитәкчесе;

3) һәлак булган хәрби хезмәткәр тәмамлаган Яр Чаллы шәһәре белем бирү оешмасының җитәкчесе.

11. Яр Чаллы шәһәре территориясендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсен карап тикшерү өчен Башкарма комитетка кәгазь рәвештәге документлар тапшырыла:

1) гражданның яки оешманың мәңгеләштерүне нигезләгән һәм мәңгеләштерүнең конкрет формасы тәкъдим ителгән гаризасы (үтенече);

2) гражданның (гариза бирүченең) паспорт күчермәсе (төп һәм теркәлү урыны);

3) язылышу (аерылышу) турында таныклык күчермәсе (хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булган хәрби хезмәткәрнең хатыны (ире) өчен);

4) вәкаләтләрне таныклаучы документның (ышаныч язуының) күчермәсе (хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булучының гаиләсенең рәсми вәкиле өчен);

5) хәрби хәрәкәтләрдә катнашуны раслый торган документ;

6) Ватанны саклаучы турында тарихи-биографик белешмә;

7) казанышларны яки һәлак булу шартларын раслый торган документларның күчермәләре (бүләкләү кәгазьләре, архив белешмәләре, үлем турында таныклык һ. б.);

8) Яр Чаллы шәһәрендә яшәү (булу) фактын раслый торган яшәү урыны яки булу урыны буенча теркәлүне исәпкә алу документы;

9) эшләрне финанслау турында инициатор оешмадан язмача йөкләмә яки финанслау мөмкинлеге/мөмкин булмау турында гражданнан белдерү кәгазе.

12. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашуны раслый торган документларга түбәндәгеләр керә:

1) Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы;

2) хәрби хәрәкәтләр ветераны таныклыгы;

3) Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу фактын раслау турында федераль башкарма хакимият органнары, федераль дәүләт органнары тарафыннан раслана торган тәртиптә, алар тарафыннан бирелә торган белешмә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу фактын билгеләү тәртибе турында» 2024 елның 9 октябрендәге 1354 номерлы Карары);

4) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариат приказыннан өземтә;

5) «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә, зат белән хәрби хезмәт узу турында контракт төзү хакында федераль башкарма хакимият органына хәбәр итү;

6) «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт күчермәсе;

7) Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле рәвештә ярдәм күрсәтү турында контракт күчермәсе;

8) хәрби билеттагы язма;

9) гражданның хәрби хәрәкәтләрдә катнашу даталарын яки чорларын раслый торган, гражданның Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узуы турында контракт күчермәсе;

10) гражданның хәрби хәрәкәтләрдә (хәрби бурычларны үтәүдә) катнашу даталарын яки чорларын раслый торган медицина белешмәләре һәм авыру тарихыннан өземтәләр;

11) хәрби хезмәткәрнең үлү турында таныклыгы (хәбәрсез югалганнар өчен).

13. Яр Чаллы шәһәре территориясендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсен карап тикшерүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) әлеге нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән кирәкле документлар булмау;

2) тапшырылган документлар дөрес булмау.

14. Комиссия, әлеге нигезләмәнең 4 бүлегендә бәян ителгән критерийларны исәпкә алып, Ватанны саклаучының истәлеген мәңгеләштерү турында карар кабул итә.

15. Гаризаны карап тикшерү срогы - Башкарма комитетта теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн.

16. Карап тикшерү йомгаклары буенча, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән Ватанны саклаучының истәлеген мәңгеләштерү турында яисә баш тарту турында карар кабул ителә. Комиссия утырышыннан соң 5 эш көне эчендә комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

17. Комиссия карары язма рәвештә гаризада бирелгән элемтә мәгълүматлары (яшәү адресы, электрон почта адресы) буенча 5 эш көне эчендә гариза бирүчегә җибәрелә.

18. Комиссия тарафыннан уңай карар кабул ителгәндә, Ватанны саклаучының истәлеген мәңгеләштерү формасы күрсәтелә, карар Ватанны саклаучының истәлеген мәңгеләштерү эшен оештыру өчен җаваплы затларга җибәрелә.

## 4 бүлек. Комиссия карарын кабул итү өчен нигез булып торучы критерийлар

19. Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү турында карар түбәндәге затларга карата кабул ителә:

1) Бөек Ватан сугышы вакытында һәлак булган;

2) Әфганстандагы сугыш һәм Кавказдагы локаль конфликтлар вакытында һәлак булган;

3) Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында һәлак булган һәм (яки) Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрелә торган районнар янәшәсендәге Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә кораллы провокация барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы бәреп керүне кире кагу буенча бурычларны үтәүче түбәндәге затлар:

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар яки махсус исемнәр бирү күздә тотылган вазыйфаларда хезмәт итү өчен мобилизация буенча Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренә җибәрелгән затлар;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узган затлар яки Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәт узган затлар;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә яки Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ихтыяри рәвештә ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән затлар яки Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм күрсәтүче оешма белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) затлар;

- федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре, федераль дәүләт органнары (Россия Федерациясе хокук саклау органнары) хезмәткәрләре, алар хезмәт бурычларын һәм башка шундый ук функцияләрне башкарганда, күрсәтелгән органнар тарафыннан җибәрелгән (җәлеп ителгән) башка затлар;

- чакырылу буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узган һәм Россия Федерациясе территориясенә (Курск, Брянск һәм Белгород өлкәләре) кораллы һөҗүмне кире кагу бурычларын үтәүдә катнашкан затлар;

4) үз намусларын һәм абруен югалтмаган, Ватанга хыянәт итмәгән, барлыкка килгән хәрби хәлләр аркасында әсирлектә вафат булган, һәлак булган Ватанны саклаучылар.

20. Ватанны саклаучының истәлеге мәңгеләштерелә, әгәр хәрби хезмәткәр:

1) Яр Чаллы шәһәреннән чакырылган булса;

2) Яр Чаллы шәһәрендә яшәгән һәм Яр Чаллы шәһәрендә җирләнгән булса;

3) Яр Чаллы шәһәрендә яшәгән, Яр Чаллы шәһәреннән чакырылган, ләкин башка муниципаль берәмлектә җирләнгән булса;

4) башка муниципаль берәмлектә яшәгән, ләкин хезмәт эшчәнлеген Яр Чаллы шәһәре оешмаларында алып барган булса (оешма җитәкчелегенең үтенече буенча);

5) башка муниципаль берәмлектә яшәгән, ләкин Яр Чаллы шәһәренең белем бирү оешмаларында укыган булса (белем бирү оешмасы җитәкчесенең үтенече буенча).

## 5 бүлек. Яр Чаллы шәһәрендә Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерүнең төп формалары

21. Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү формалары:

1) исемне «Ватан-ана» мемориаль комплексының хәтер стенасына язу;

2) мемориаль такта, һәйкәл, стела, обелиск, бюст урнаштыру;

3) хәрби каберлек яки мемориаль зона булдыру, саклау, төзекләндерү;

4) мәңгеләштерүнең Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары белән тыелмаган башка формалары.

Башкарма комитетАппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2026 елның 19 июнендәге
6167 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә
Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия
составы

| №<br>т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Салахов<br>Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Харисов<br>Винер Хәмит улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 3. | Хәлимов<br>Рамил Мәрван улы | комиссия рәисе урынбасары, шәһәр Хакиме ярдәмчесе (килешү буенча) |
| 4. | Видинеева<br>Ләйсән Әлфит кызы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| | комиссия әгъзалары | |
| 5. | Әхмәтҗанов<br>Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 6. | Вәлиев<br>Дамир Шамил улы | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол районы һәм Тукай районы хәрби комиссариатының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| 7. | Вилданов<br>Руслан Флер улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 8. | Ильясов<br>Рәшид Флүр улы | Яр Чаллы шәһәренең Үзәк һәм Автозавод районнары хәрби комиссариатының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| 9. | Кәрамиев<br>Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 10. | Кашапов<br>Нәркиз Венер улы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| 11. | Мулюкова<br>Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| 12. | Певгова<br>Татьяна Анатольевна | Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе директоры |
| 13. | Уткин<br>Артем Иванович | «Мәдәният һәм ял паркы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең генераль директоры (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 14. | Хәбибуллин<br>Фидәрис Фәндәвис улы | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |
| 15. | Хөснуллин<br>Айрат Шәукәт улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |

Башкарма комитетАппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева